Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлегенең Рус Чиябашы авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 30 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 18 номерлы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 окябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлегенең Рус Чиябашы авылында гражданнар җыенының 2019 елның 29 ноябрендәге 3 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге составына керүче Рус Чиябашы һәм Татар Чиябашы авылларында гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, хезмәт күрсәтү һәм урам утларын кулланган энергия чыгымнарына-180 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын төзү ,карап тоту, ремонтлау һәм су башнялары территориясен койма белән әйләндереп алу, суның лаборатор-инструменталь тикшеренүләренә түләү ,су алу өчен ярымгайкалар сатып алуга - 205 сум;

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, вак таш өю, торак пунктлар эчендәге юлларны һәм урамнарны чүп-чардан арындыру ,

урамнарны грейдлау , кышкы чорда урамнарны кардан чистарту , чүплекләрне өемләү) - 180 сум;

- каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә һәм контейнерлар сатып алуга бәйле чыгымнарга ,белгеч эшенә түләү-35 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

-урамнарны яктырту өчен кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, хезмәт күрсәтүгә һәм урам утларын кулланган энергиягә чыгымнарны түләүгә – 180 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын төзү ,карап тоту, ремонтлау һәм су башнялары территориясен койма белән әйләндереп алу, суның лаборатор-инструменталь тикшеренүләренә түләү ,су алу өчен ярымгайкалар сатып алуга - 205 сум;

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, вак таш өю, торак пунктлар эчендәге юлларны һәм урамнарны чүп-чардан арындыру , урамнарны грейдлау , кышкы чорда урамнарны кардан чистарту , чүплекләрне өемләү) - 180 сум;

- каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә һәм контейнерлар сатып алуга бәйле чыгымнарга ,белгеч эшенә түләү-35 сум;

4.Халык җыены нәтиҗәләрен Чиябаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлеге башлыгы: И. З. Сәмигуллин